**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"27" ноябрь 2020 ел. №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 27 ноябрендә «Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән,тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Кызыл Утар авылы территориясендә үләнне чабу һәм чистарту;
- "Әшрәп" чишмәсен ремонтлау, (төзелеш материаллары сатып алу, чишмәгә кадәр төшү өчен тимер баскыч урнаштыру, килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- Кызыл Утар авылы коелары өчен коймалар урнаштыру (килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- Урам утын карауга хезмәт хакы түләү.

2) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Кызыл Утар авылы зиратында куаклар кисү, үләннәр һәм үсемлекләр чабу. (килешү буенча хезмәт хакы түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 65 (алтмыш биш) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 53 (илле өч) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 53 (илле өч) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. "Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның

җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Кызыл Утар авылы территориясендә үләнне чабу һәм чистарту;
- "Әшрәп" чишмәсен ремонтлау, (төзелеш материаллары сатып алу, чишмәгә кадәр төшү өчен тимер баскыч урнаштыру, килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- Кызыл Утар авылы коелары өчен коймалар урнаштыру (килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- Урам утын карауга хезмәт хакы түләү.
2) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:
- Кызыл Утар авылы зиратында куаклар кисү, үләннәр һәм үсемлекләр чабу. (килешү буенча хезмәт хакы түләү).

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Шакирова Р.Ф.

Совет Кшкловского сельского поселения
Кышлау авыл җирлеге Советы